ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘМБАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2024 ел, 3 июнь №153

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 гыйнварындагы 96 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «17390» санын «18260» санына алмаштырырга;

1.2 пунктының «а» пунктчасында «13420» санын «19569» саннарына, «9,26» санын «12,86» саннарына алмаштырырга;

2.2 пунктта «12688» санын «13323» санына алмаштырырга;

2.4 пунктының 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктының 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгы,
Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы рәисе Миннуллин Ф.Ф.